АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«20»декабрь» 2016 г. № 46

Казан

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет хакында Нигезләмәне раслау турында

2014 елның 21 июлендәге «Россия Федерациясендә Иҗтимагый контроль нигезләре турында»гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы «Министерство, дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы идарәсе каршындагы иҗтимагый совет турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 октябрендәге 856 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы, 2014 елның 20 сентябрендәге 669 номерлы, 2015 елның 14 маендагы 341 номерлы, 2015 елның 5 сентябрендәге 643 номерлы, 2015 елның 17 ноябрендәге 862 номерлы каралары керткән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) туры китерү максатыннан боерам:

1. Түбәндә беркетелгән Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы Иҗтимагый Совет турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Юридик бүлекнең төп киңәшчесе О.А.Карповка бу боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И.Минуллина

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгы
Приказы белән расланган
20 декабрь 2016 ел № 46

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләр**

1.2 Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы киңәшү органы булып тора, ул Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарның, иҗтимагый һәм башка төр коммерцияле булмаган оешмаларның инвестицияләр җәлеп итү буенча дәүләт сәясәтен формалаштыру һәм тормышка ашыруны гамәлгә керткәндә, инвестицион проектларны эш барышында күзәтеп барганда, Татарстан Республикасында дәүләт күләмендәге һәм шәхси партнерлык өлкәсендә уңайлы инвестицион климат тудырганда һәм аны кызыклы итү буенча хезмәт куйгандагы хокуклары һәм иреге, шулай ук Татарстан Республикасы Инвестицион агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы әлеге Нигезләмә күздә тоткан башка кайбер вәкаләтләрне дә үти.
1.2. Иҗтимагый советның составы һәм исәбе Агентлык указы белән билгеләнә.
1.3. Иҗимагый совет эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты боерыклары һәм боерыкнамәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты боерыклары һәм боерыкнамәләренә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте каралары һәм боерыкнамәләренә, шулай ук Татарстан Республикасы Инвестицион агентлыгы каршындагы Иҗтимагый советның Нигезләмәсенә таяна.
1.4. Иҗтимагый советның карарлары тәкъдим итү характерында булырга тиешләр.
1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычны исәптә тотып алып бара.
1.6. Иҗтимагый советның эше ихтыяри нигездә алып барыла, шулай ук ачыклык, партнерлык, һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы закончалыклары белән тәңгәл китереп башкарыла.
1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданлык җәмгыяте вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм матбугат

чараларының үзара кызыксынуы нигезендә алып барыла.

## 2. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1 Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып түбәндәгеләр исәпләнә:

- гражданнарның ихтыяҗларын һәм теләкләрен исәптә тоту, Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарның, иҗтимагый һәм башка төр коммерцияле булмаган оешмаларның инвестицияләр җәлеп итү буенча дәүләт сәясәтен формалаштыру һәм тормышка ашыруны гамәлгә керткәндә, инвестицион проектларны эш барышында күзәтеп барганда, Татарстан Республикасында дәүләт күләмендәге һәм шәхси партнерлык өлкәсендә уңайлы инвестицион климат тудырганда һәм аны кызыклы итү буенча хезмәт куйгандагы хокукларын һәм иреген яклау;
- Агентлык эш сферасына карый торган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшкәрткәндә иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади берләшмәләрне җәлеп итү, Агентлык эшчәнлеген ачыклык һәм һәркемгә билгеле булуын тәэмин итү;
- Агентлык эшчәнлеге сферасында ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары:

- Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарның, иҗтимагый һәм башка төр коммерцияле булмаган оешмаларның инвестицияләр җәлеп итү буенча дәүләт сәясәтен формалаштыру һәм тормышка ашыруны гамәлгә керткәндә, инвестицион проектларны эш барышында күзәтеп барганда, Татарстан Республикасында дәүләт күләмендәге һәм шәхси партнерлык өлкәсендә уңайлы инвестицион климат тудырганда һәм аны кызыклы итү буенча хезмәт куюны камилләштерү буенча киңәшләр әзерләү;
- Агентлык эшчәнлеге сферасына караган мәсьәләр буенча норматив хокукый актларның проектына иҗтимагый экспертиза ясау, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хөкүмәтенең башкарма органнары эшләгән дәүләт программалары проектлары хакында фикер алышу;
- Агентлык тарафыннан карарлар кабул иткәндә, киң җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын җайга салу;
-җәмәгатьчелекнең Агнетлык эшчәнлеге буенча күбрәк мәгълүматка ия булу мөмкинлеген тәэмин итү.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары эшчәнлегенең нәтиҗәләренә , шулай ук Россия Федерациясендәге сәяси һәм иҗтимагый ситуациягә бәйле рәвештә үзгәрә һәм тулыландырыла ала.

## 3. Иҗтимагый советның составы

3.1. Иҗтимагый совет гражданнар, иҗтимагый оешмалар һәм коммерцияле

булмаган оешмаларның тәкъдимнәренә нигезләнеп, рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм Агентлык каршындагы Иҗтимагый совет әгъзалары составында формалаша.

3.2. Иҗтимагый совет ихтыяри нигездә катнашучылардан 12 кеше исәбендә формалаша.

3.3. Иҗтимагый совет составына иҗтимагый оемаларның һәм башка социаль юнәлештәге коммерцияле булмаган оешмаларның вәкилләре саналган гражданнар керә ала. Аларның һөнәри сыйфатлары, моннан тыш, Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләрне хәл итү өчен зарури булган белемнәре, әлеге сферадагы эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына беренче абзацның гамәлдәге пунктында искә алынган затлар белән беррәттән, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдим иткән затлар да кертелергә мөмкин. Алар Иҗтимагый советның гомум санының яртысын тәшкил итә алалар.

Иҗтимагый совет составына Элек Россия Федерациясе дәүләт хезмәтендә, Россия Федерациясе гражданлык хезмәтендә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дүләт хезмәтендә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының гражданлык хезмәтендә хезмәт куючылар, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаручылар Иҗтимагый советның гомум санынннан биштән бердән артыграк булмаслык исәптә керә алалар.

3.4. Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар: Росси Федерациясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын алыштыручылар, Россия Федерациясе гражданлык хезмәте вазыйфаларын алыштыручылар, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт хезмәте вазыйфаларын алыштыручылар, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының гражданлык хезмәте вазыйфаларын алыштыручылар, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаручылар, суд хөкеме тарафыннан эшкә сәләтсез дип табылган затлар, суд тарафыннан чыгарлыган хөкем карары өсләрендә торган затлар, шулай ук 2005 елның 4 апреленнән гамәлгә кергән «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турындагы» 32 нче номерлы Федераль Закон нигезенә бәйле кайбер затлар.

3.5. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәиснең урынбасары Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү ысулы белән Иҗтимагый советның беренче утырышында сайлана, алар өчен Иҗтимагый советның яртысыннан артыгының тавыш бирүе зарури. Рәиснең һәм рәис урынбасарының сайлануы турындагы карар Иҗтимагый советның беркетмәсендә теркәлә.

Иҗтимагый совет рәисенең һәм рәис урынбасарының үз вазыйфасыннын азат ителүе мәсьәләсе Агентлык җитәкчесе мөрәҗәгате буенча карала, шулай ук Иҗтимагый советка аларның шәхси гаризалары яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының биштән бере мөрәҗәгате нигезендә дә каралырга мөмкин.

Иҗтимагый совет әгъзаларының яртысыннан артыгы хуплап тавыш бирсә,

карар кабул ителгән дип санала.
3.6. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләте туктатыла:
- алар Иҗтимагый советтан чыгам диеп гариза бирсә;
- сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмасалар, яки бу эштән башка сәбәпләр буенча баш тарсталар;
- алар исеменә суд тарафыннан гаепләү карары чыгарылсы;
- суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип табылсалар яки билгесез сәбәпләр буенча совет эшчәнлегендә катнашмасалар һәм бу карар гамәлгә кертелсә;
- Иҗтимагый совет әгъзалары тарафыннан кабул ителгән этик кануннарны үтәмәсәләр, һәм моны раслау утырышта катнашкан күпчелек совет әгъзасы тарафыннан башкарылса;
- Россия Федерациясе гражданы булудан туктасалар;
- Системалы рәвештә (3 тапкырдан артыграк) Иҗтимагый совет эшчәнлегендә гафу ителерлек сәбәптән тыш катнашмасалар;
- Иҗтимагый совет рәисе һәм аның урынбасары тарафыннан бирелгән йөкләмләрне системалы рәвештә (2 тапкырдан артыграк) гафу ителерлек сәсбәбе булган очракта да үтәмәсәләр;
- Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә, Россия Федерациясе гражданлык хезмәтенә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт хезмәтенә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының гражданлык хезмәтенә кабул ителсәләр, муниципаль вазыйфаларга һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаруга җәлеп ителсәләр;
- Чит ил дәүләте гражданлыгын алсалар.
3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы булудан азат итәр өчен Агентлык тарафыннан карар булуы зарур. Бу Иҗтимагый совет әгъзасының кулдан язылган гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе, йә булмаса аның урынбасарының кулдан язылган гаризасы нигезендә кабул ителә. Шулай ук карар кабул ителүгә әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында санап үтелгән шартлар да нигез була ала.
Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге какшау нәтиҗәсендә, гамәлгә кергән суд карары, Россия Федерациясе гражданлыгын алыштыру нәтиҗәсендә совет эшчәнлегендә катнаша алмый икән, болар хакында кичекмәстән совет рәисенә, йә булмаса аның урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.
3.8. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Агентлык җитәкчесе тарафыннан Иҗтимагый совет рәисе түбәндәгеләрне тәкъдим иткән очракта туктатыла:
- Россия Федерациясенең җинаять эшләре процессуаль закончалыгы тарафыннан җинаять кылуда гаепләнү карары гамәлгә кертелүе турында билгеле булса;
- административ хөкем карары нигезендә административ кулга алыну билгеләнсә;
- закон чыгару (сайлап куелган) дәүләт хакимияте органына депутатлыкка

кандидат, җирле үзидарә органына сайлау вазыйфасына кандидат, сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле яки ышаныч белдерелгән заты буларак теркәлсә, шулай ук Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасында референдумнар үткәрү буенча җаваплы инициатив төркемнең составына кертелүе билгеле булса.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1.Иҗтимагый совет әгъзасы хокуклы:
- Агентлык инициативасы белән уздырылган барлык чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, «түгәрәк өстәл»ләр һ.б.) катнашырга, дәүләт куркынычсызлыгына кагылышлы һәм яшерен, шәхси, тыелган һәм дәүләт тарафыннан чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган махсус чараларны исәпкә алмыйбыз;
- инициатив рәвештә Иҗтимагый советка аналитик запискалар, докладлар һәм башка төр мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләп җибәрергә;
- Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый совет эшчәнлегенең планына һәм аның утырышлары уздырылу тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;
- Көн тәрбиенә чыгарылган мәсьәләләрне хәл иткәндә Иҗтимагый совет утырышларын чакырылырга тиешле затларның кандидатураларын күрсәтергә.
4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы тиешле:
- Иҗтимагый совет рәисе йөкләгән вазыйфаларны башкарырга;
- әлеге Нигезләмә тарафыннан расланган һәм Иҗтимагый совет эшчәнлегенең нигезен тәшкил иткән эш тәртибен үтәргә;
- Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән үзе катнашырга;
- Иҗтимагый совет үз алдына куелган бурычларны хәл итәр өчен оештырган эксперт, эшче төркемнәрнең, комиссия, органнарның эшчәнлегендә катнашырга;

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген Иҗтимагый совет утырышында Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан тәкъдим ителеп, гамәлгә куелган планнар һәм программалар нигезендә оештыра;
5.2. Иҗтимагый совет эшчәнлеген Иҗтимагый совет әгъзалары, рәисе һәм Агентлык тәкъдимнәре ниезендә планлаштыра;
5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер мәртәбә уздырыла. Иҗтимагый совет утыршларында кабул ителгән карарлар беркетмәдә теркәлә.
Иҗтимагый совет утыршлары тагын Агентлык инициативасы белән дә уздырыларга мөмкин, бу очракта Агентлык норматив хокукый актлар исемлеге һәм башка документлар таләп иткән буенча эшләгән норматив хокукый актларның проектларын, Татарстан Республикасы башкарма органнары тәкъдим иткән башка төр документларны карауны һәм үзара килешеп эш итүне күздә тота. Әлеге документлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

29.03.2013 «Татарстан Республикасы хакимиятенең башкарма органнарының иҗтимагый советларда һәм югарыда искә алынган хакимиятнең башкарма органнарында алдан фикер алышмыйча кабул ителергә тиеш булмаган норматив хокукый актлар һәм башка документлар» турындагы 214 нче номерлы Карары буенча совет утырышына куелырга тиешләр.
5.4. Иҗтимагый совет утырышлары аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының икедән бер өлеше катнашса карар чыгарырга хокуклы исәпләнә. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта үзе катнаша алмаса, көн тәртибенә чыгрылган мәсьәләләр буенча үз тавышын яки фикерен хат, факсимиле рәвешендә, электрон почта аша Иҗтимагый советның башка әгъзасына тапшыра ала. Әмма бу хакта Иҗтимагый советның рәисен, йә блумаса Иҗтимагый советның җаваплы секретарен алдан кисәтеп кую зарур. Шул рәвешле, утырышта катнашучылар исемлегенә үз тавышын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган әгъзалар да кертеп карала.
Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәдәге 5.3 пунктның икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар (норматив хокукый актлар) Агентлык һәм Иҗтимагый советка юлланганнан соң, 10 календарь көн эчендә каралларга тиешле. Иҗтимагый советның бәяләмәсен алу максатыннан тавыш бирүне уздыру читтә нтавыш бирү формасында узарга да мөмкин, тавышлар беркетмәсгә кертелә, беркетмә, үз чиратында, Иҗтимагый совет рәисе, ул югында аның урынбасары тарафыннан имзалана. Мондый тавыш бирү документларны почта аша алышу юлы белән дә, телеграф, телетайп, телефон, электрон почта аша һәм башка төрле дә башкарыла ала, иң мөһиме - юлланган мәгълүматларның һәм кабул ителгән хәбәрләр белән аларны ныгытучы докуентларның аутентиклыгы гына сакланырга тиеш. Читтән тавыш бирү ысулын кулланганда, Иҗтимагый совет рәисенә һәм советның барлык әгъзаларына көн тәртибе, нормотив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) җибәрелә, болар буенча Иҗтимагый совет нәтиҗәне совет утырышы узганнан соң, җиде календарь көн эчендә ясарга тиеш. Иҗтимагый совет әгъзалары, кирәк дип тапсалар, Агентлыктан каралырга тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәм материаллар һәм мәгълүматларны сорап алырга мөмкиннәр.
Иҗтимагый совет каралары күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә.
5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе уздыра, ул булмаганда - Иҗтимагый совет рәисенең урныбасары.
5.6. Иҗтимагый совет карарлары, аларга йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләргә бәйле рәвештә, тәкъдим итү характерында булалар һәм башкаларга Иҗтимагый совет беркетмәсеннән өземтә рәвешендә җиткереләләр, Иҗтимагый совет кирәк тапса, башка ысуллар да каралырга мөмкин.
5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат Агентлыкның сайтында һәм мәгълүмати-телекоуммуникация Интернет челтәрендә урнаштырылып бара.
5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

- Иҗтимагый совет эшчәнлеген җитәкләү белән шөгыльләнә;
- Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;
- Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советның эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә, аларны Иҗтимагый советка расларга тәкъдим итә;
- Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;
- Иҗтимагый советның көн тәртибен раслый;
- Иҗтимагый советның тәкъдимнамәләрен, беркетмәләрен һәм башка документларын имзалый;
- Иҗтимагый совет утырышларын уздыру урынын һәм вакытын билгели;
- Иҗтимагый совет эшчәнлеге кысаларында, үзенә йөкләнгән максатлар һәм бурычларга бәйле рәвештә, Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр тапшыра;
- Иҗтимагый совет исеменнән сораулар, тәкъдимнамәләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;
- Иҗтимагый советның эшчәнлеген алып бару өчен кирәк булган башка вазыйфаларны башкара.

5.9. Иҗтимагый совет рәисенең урынбасары:
- Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә ялда булганда, яки үз вазыйфаларын башкара алмаганда, аның вазыйфаларын үти;
- Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;
- Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен әзерли, аны Иҗтимагый совет рәисенә расларга тәкъдим итә;
- Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый советның эшчәнлеген алып бару өчен кирәк булган башка вазыйфаларны башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:
- утырышларга материаллар һәм кабул ителгән карарларның проектларын әзерли;
- Иҗтимагый совет әгъзаларына аның кайда һәм кайчан үтәсен хәбәр итә, көн тәртибен әзерли, утырыш барышында әгъзаларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материал белән тәэмин итә.

Агентлык белән Иҗтимагый совет арасындагы эшләрне җайга сала һәм тәртиптә тота;
- Иҗтимагый совет эшчәнлегенең документаль-техник яктан тәэмин ителешен оештыра;
- Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның тормышка ашуын контрольдә тота;
- Иҗтимагый советның көн тәртибен әзерләүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңланачак һәм каралачак мәсьәләләр буенча эшче, эксперт һәм башка эшлекле органнарга берләшеп, материаллар әзерләгәндә, Иҗтимагый совет сотавына кермәгән белгечләрне чакыра алалар. Бу Иҗтимагый совет рәисе урынбасары

белән хәл итеп эшләнә.
5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына нинди дә булса мәгълүмат һәм бәяләмә алу өчен, башкарма органнардан, коммерцияле булмаган оешмалардан, фәнни учреждениеләрдән вәкилләр, экспертлар һәм белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзасы булмаган массакүләм мәгълүмат чараларының әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет тарафыннан махсус чакырылган очракта гына катнаша ала.
5.13. Иҗтимагый советка каралырга кергән материаллар Иҗтимагый совет рәисенә алар каралачак чираттагы утырышның билгеләнгән вакытына кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материаллар соңрак тапшырылган очракта, бу хәл Иҗтимагый совет рәисе, йә булмаса аның урынбасары белән килешенә.
5.14. Иҗтимагый советның техник һәм оештыру эшчәнлеген Агентлык тәэмин итә.